**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 30 гыйнварындагы 284 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4726 номерлы «Казан шәһәре территориясендә җир кишәрлекләрен арендалау, сату-алу, җирдән бушлай файдалану килешүләренең типлаштырылган формаларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Килешүләренең типлаштырылган формаларын законнарга туры китерү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4726 номерлы «Казан шәһәре территориясендә җир кишәрлекләрен арендалау, сату-алу, җирдән бушлай файдалану килешүләренең типлаштырылган формаларын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 3 мартындагы 563 номерлы, 2019 елның 29 гыйнварындагы 352 номерлы, 2020 елның 26 июнендәге 1732 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 1819 номерлы, 2023 елның 4 августындагы 2201 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. җир кишәрлеген арендалау буенча сатулар үткәрмичә төзелә торган килешүнең типлаштырылган формасында (1 номерлы кушымта):

1.1.1. түбәндәге эчтәлекле 3.6.1 пунктча өстәргә:

«3.6.1. Җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәргәндә, аренда түләве җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәргән елдан соң килүче елның 1 гыйнварына яңадан исәпләнергә тиеш;»

1.1.2. түбәндәге эчтәлектәге 3.6.2 пунктча өстәргә:

«3.6.2. Аренда түләве ел саен, ләкин җир кишәрлеген арендалау килешүе төзелгәннән соң бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта, берьяклы тәртиптә арендага бирүче тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турындагы федераль законда билгеләнгән инфляция дәрәҗәсе

күләменә үзгәртелә, ул җир кишәрлеген арендалау килешүе төзелгән елдан соң килә торган елдан башлап, чираттагы финанс елы башына карата ел саен кулланыла.

Арендалана торган җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәргән елда аренда түләвен инфляция күләменә үзгәртү гамәлгә ашырылмый»;

1.2. аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда төзелә торган җир кишәрлеген арендалау килешүенең типлаштырылган формасында (2 номерлы кушымта ):

1.2.1. түбәндәге эчтәлектәге 3.2.1 пунктча өстәргә:

«3.2.1. Аренда түләве ел саен, ләкин җир кишәрлеген арендалау килешүе төзелгәннән соң бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта, берьяклы тәртиптә арендага бирүче тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турындагы федераль законда билгеләнгән инфляция дәрәҗәсе күләменә үзгәртелә, ул җир кишәрлеген арендалау килешүе төзелгән елдан соң килә торган елдан башлап, чираттагы финанс елы башына карата ел саен кулланыла»;

1.2.2. 8.5 пунктында «1.4.2» саннарын «1.4.1» саннарына алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**